ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясепоселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

08.07.2024 № 637

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Алты яшь тә алты айдан кечерәк һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларына беренче сыйныфка кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 27 февралендәге 520 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы Боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 февралендәге 520 номерлы карары (10.06.2020 № 471, 20.06.2022 № 604, 13.06.2023 № 749 карарлары редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларына беренче сыйныфка агымдагы елның 1 сентябренә алты яшь тә алты айдан кечерәк һәм сигез яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итү турында ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаризаларны карау буенча комиссия составын (2 нче кушымта) яңа редакциядә Кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Д.Ф. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 08 июле 637нче
номерлы карарына кушымта

Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларына беренче сыйныфка агымдагы елның 1 сентябренә алты яшь тә алты айдан кечерәк һәм сигез яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итү турында ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаризаларны карау буенча комиссия составы

1) Д.Ф. Шәйдуллин - ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;
2) И.А. Халитов - Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;
3) Р.Х. Хайруллина - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнең башлангыч белем буенча методисты, комиссия секретаре;
4) А.И. Әбубакирова - ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы мөдире;
5) Э.А. Усманова - ТР Биектау муниципаль районы муниципаль психологик-педагогик хезмәте җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы;
6) В.В. Хөсәинова - ТР Биектау муниципаль районы муниципаль психологик-педагогик хезмәтенең педагог-психологы;
7) Г.И. Ганеева - «Биектау ЦРБ» ДАССУ район педиатры.